| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮҖӘКӘ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ | | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА КУЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА |
|---|---|---|
| 423734, Күҗәкә авылы, Совет ур., 28 нче йорт. Тел.3-44-48 | | 423734, село Кузякино, ул. Советская,дом 28, Тел. 3-44-48 |

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**01 ноябрь 2019 ел** **№2**

Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлегенең Күҗәкә,Адай,Иске Урьяды,Түбән Урьяды торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Күҗәкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Күҗәкә авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 14 ноябренә Күҗәкә авылында билгеләргә.

2. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 16 ноябренә Адай авылында билгеләргә.

3. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 19 ноябренә Иске Урьяды,Түбән Урьяды авылларында билгеләргә

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне распарга:

1.Һәйкәлләр территориясен төзекләндерү һәм ремонтлау;
2.Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру:
- рәсми физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм массакүләм чараларны оештыру һәм уздыру ;
3.Оештыру чикләрендә җирлек халыкны су белән тәэмин итү:
- торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау,коймалар тоту һәм лицензияләү;

4.Җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:
- урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;

5. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдерлау, кардан чистарту);
6. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту :
- зират коймасын ремонтлау;
- күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү.

"ӘЙЕ" "ЮК"

3. 2019 елның 14 ноябрендә халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Күҗәкә авылы, Совет урамы, 28 нче йорт, 2019 елның 16 ноябрендә түбәндәге адрес буенча үткәрерә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Адай авылы, Горький урамы, 2 нче йорт, 2019 елның 19 ноябрендә түбәндәге адрес буенча үткәрерә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Иске Урьяды авылы , Совет урамы, 23 нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Күҗәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Н.Мусин

Совет КУЗЯКИНСКОГО сельского поселения
ИНН 1604001094